Татарстан Республикасы

АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ

«УРМАНДӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»

МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

КАРАР

№ 4 09.11.2021 ел

« Татарстван Республикасы Аксубай муниципаль районы Урмандәй авыл җирлегенең ) Урмандәй авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы «Урмандәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Урмандәй авыл җирлегенең ) - Урмандәй авылында яшәүче гражданнар өчен 2021 елның 19 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«2022 елда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Урмандәй авыл җирлегенең Урмандәй авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган торучыдан, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертүегез белән һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча юнәлдерү белән, Сез килешәсезме:

1) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Урмандәй авылы өчен вак таш, вак таш сатып алу (сатып алу, ташу)
- юлларны кышкы карап тоту (килешү буенча эшләр өчен түләү).

2) каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым җыю) һәм транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнашу:

- контейнер мәйданчыклары төзү (материал сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү).

3) территорияне төзекләндерү:

- трактор өчен запас частьләр сатып алу.

4) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту

- Урмандәй авылы зиратын койма белән әйләндереп алу (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Гражданнар җыеннарын оештыру һәм үткәрү өчен Урмандәй авыл җирлеге башкарма комитетына җаваплылык йөкләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Урмандәй авыл җирлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aksubaevo.tatar.ru һәм Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Урмандәй авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

5. Әлеге карар кабул ителгән көннән үз көченә керә.

Урмандәй авыл җирлеге башлыгы: В.З.Николаев